**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 15 августындагы 3368 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 25 апрелендәге 1597 номерлы «Тантаналы шартларда өйләнешүне дәүләт тарафыннан теркәү эшчәнлеген оештыру турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Өйләнешүче затлар теләге буенча өйләнешүне тантаналы шартларда дәүләт теркәвенә алу өчен урыннар санын арттыру максатыннан һәм 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы «Гражданнар хәле актлары турында»гы федераль законның 27 статьясының 5 пункты нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 25 апрелендәге 1597 номерлы «Тантаналы шартларда өйләнешүне дәүләт тарафыннан теркәү эшчәнлеген оештыру турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 пунктта «(теркәлә)» сүзен «(1 номерлы кушымта)» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. түбәндәге эчтәлекле 1(1) пунктын өстәргә:

«1(1). Тантаналы шартлардагы өйләнешү тантанасында катнашучыларның үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен расларга (2 номерлы кушымта)»;

1.3. кушымтаны 1 номерлы кушымта дип санарга һәм аңа түбәндәге эчтәлекле 5 пунктны өстәргә:

«5. Өйләнешергә теләүче затларның сайлап алуы буенча Казан шәһәренең башка мәдәни һәм күңел ачу объектлары»;

1.4. әлеге карарның кушымтасы нигезендәге редакциядә 2 номерлы кушымта өстәргә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 15 августындагы
3368 номерлы карарына
кушымта

**Тантаналы шартлардагы өйләнешү тантанасында катнашучыларның үз-үзләрен тоту кагыйдәләре**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 16 декабрендәге 4483 номерлы «“Казан шәһәренең Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе”» муниципаль казна учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар турында»гы карарына кушымта нигезендә тантаналы чараларны күчмә үткәрү түләүле нигездә күрсәтелә.

2. Тантанада өйләнешүче затлар һәм аларның кунаклары (туганнары, дуслары), Казан шәһәре Башкарма комитетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе хезмәткәре катнаша.

3. Тантанада катнашучылар тантаналы теркәү залларындагы мөлкәттән билгеләнеше нигезендә файдаланырга хокуклы һәм аңа сак карарга тиеш. Бүлмәләрнең интерьер композициясен (җиһазларны һәм интерьерның башка әйберләрен күчерү) һәм тәрәзәләрне бизәү әйберләрен бозу рөхсәт ителми, зал җиһазларына басу, аңа чәчәкләр, кулчатыр кую, зал җиһазларында чүп һәм сагыз калдыру тыела. Мөлкәтнең югалуына, өлешчә җимерелүенә яисә башлангыч тышкы кыяфәтенең бозылуына китергән бозу очракларында, гаепле затлар административ хокук бозулар турындагы законнар нигезендә җаваплы була, шуннан соң мөлкәти зыянны каплый.

4. Тантаналы теркәү залында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Дәүләт символикасы предметлары: дәүләт флаглары һәм дәүләт герблары, шулай ук Казан шәһәре флагы һәм гербы урнаштырылырга тиеш.

Өйләнешүне дәүләт теркәвенә алганда тантаналы шартларда мәдәни һәм күңел ачу объектларының техник чараларын кулланып, локацияне музыкаль озата бару һәм җиһазлау тәэмин ителергә тиеш. Моннан тыш, регистратор өчен микрофон һәм документлар өчен стойка булу мәҗбүри.

5. Тантаналы теркәү залында түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

- зур габаритлы әйберләр (шул исәптән бүләкләр, кул йөге һ.б.) белән керү;
- тәмәке тарту һәм спиртлы эчемлекләр эчү, исерек хәлдә килү;
- тантананы уздыруның үз сценариен тагу;

- тантаналы теркәү залында өске киемдә булу;

- зал буйлап йөрү, шулай ук тантаналы чара вакытында залга керү һәм чыгу;

- ярма, чәчәк таҗлары, тәңкәләр, конфетлар һ.б. сибү;

- пиротехника куллану, бәхетсезлек очракларын булдырмау өчен фужерлар бәрү;

- мобиль элемтәдән куллану;

- тантана залына тантанага чакыручы бүлек белгечләренең тәкъдимнәрен игътибарсыз калдыру;

- тантаналы теркәү залыннан тыш, бүлекнең эш кабинетларында, хезмәткәрләр бүлмәләрендә рәсемгә төшерү;

- тантаналы чаралар үткәрү графигын бозуга китерерлек башка гамәлләр кылу.

6. Өйләнүшече затлар, шулай ук алар тарафыннан чакырылган кунаклар мәдәни-күңел ачу учреждениесенең тантаналы теркәү залында булганда:

- Гражданлык хәле актларын теркәү органы хезмәткәренең тантананы үткәрү тәртибенә кагылышлы тәкъдимнәрен үтәргә;

- мәдәни-күңел ачу учреждениесен тантаналы теркәү залындагы мөлкәттән аның билгеләнеше буенча файдаланырга;

- җәмәгать тәртибе кагыйдәләрен һәм үз-үзеңне тотуның этик нормаларын үтәргә бурычлы.

7. Казан шәһәре Башкарма комитетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе хезмәткәрләре тантаналы чара кысаларында гражданлык хәле актын дәүләт теркәвенә алалар.

8. Өйләнешүне тантаналы шартларда дәүләт теркәвенә алуга тотыла торган вакыт, өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу өчен кирәкле документларны тикшерү һәм рәсмиләштерү, өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу тантанасын тантаналы шартларда үткәрү вакытының озынлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының 2018 елның 28 декабрендәге 307 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе территориясендә Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында билгеләнгән вакыттан артмаска тиеш.

9. Өйләнешүне тантаналы шартларда, шул исәптән мәдәни-күңел ачу учреждениесе территориясендә дәүләт теркәве график нигезендә билгеләнгән вакытта үткәрелә һәм катнашучылар соңга калу сәбәпле кичектерелми.

_______________